**СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Дубъязы, ул. Ленина, 28

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

Тел./факс: +7(84365) 76-5-45, e-mail: Brl.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**07 сентябрь, 2021 ел** **№ 35**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Конституция Судының 2021 елның 19 апрелендәге 14-П номерлы карары, «Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Дөбъяз авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2020 елның 15 маендагы 162 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә, 125 пунктындагы 14 абзацны төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе ур.,
Авыл җирлеге башлыгы ур. И.Ф.Бариев